КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 31 гыйнвар г.Казань № 61

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр рәвешендә бирелә торган акчадан файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2009 ел, 26 декабрь, 1208 нче карары белән расланган Социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр рәвешендә бирелә торган акчадан файдалану кагыйдәләренә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр рәвешендә бирелә торган акчадан файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2009 ел, 26 декабрь, 1208 нче карары белән расланган Социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр рәвешендә бирелә торган акчадан файдалану кагыйдәләренә, 6 пунктта «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Республика ресурс 2 үзәге» сүзләрен «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Бу карарның гамәлдә булуы 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин